КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июль г.Казань № 684

Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 15 июль, 684 нче
карары белән расланды

Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – шул ук эзлеклелектә муниципаль берәмлекләр, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 пунктында каралган максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү һәм аларны тоту шартлары:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының муниципаль берәмлек территориясендә бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү турында карары булу;

б) бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өлешендә чыгым йөкләмәләрен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

в) муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

г) бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәге вәкаләтле органы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – шул ук эзлеклелектә килешү, вәкаләтле орган) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен вәкаләтле орган Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка;

муниципаль берәмлекнең бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өлешендә чыгым йөкләмәләрен билгели торган хокукый актының расланган күчермәсен;

муниципаль берәмлектәге вәкаләтле органның агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турындагы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында бюстларны урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү чыгымнарына түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган өземтә.

7. Вәкаләтле органыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә карап тикшерелә. Документларны карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документларны кабул итмәү турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документларны кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау яки бу Тәртипнең 6 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшыру;

вәкаләтле орган тарафыннан бу Тәртипнең 5 пунктында каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү.

Министрлык бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта вәкаләтле органга, кабул итмәү сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылган документларын кабул итмәү турында хәбәр итә.

Вәкаләтле орган элек тапшырылган документларны кабул итмәү турында хәбәрнамә алган көннән 10 көн эчендә бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән документларны яңадан тапшырырга хокуклы.

8. $i$ муниципаль берәмлек ($C_i$) бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = P_1 + P_2,$$

монда:

$P_1$ – Россия Федерациясе территориясендә сынлы сәнгать әсәрләрен иҗат итү кыйммәтен билгеләү методикасы һәм расланган федераль төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган бюстларны урнаштыру (аларны иҗат итүне кертеп) чыгымнары;

$P_2$ – расланган федераль төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган янәшәдәге территорияне төзекләндерү чыгымнары.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертлар күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара транс-

фертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертлар алучының башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе;

башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

11. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетына күчерелә.

12. Вәкаләтле орган, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5 еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка килешүдә билгеләнә торган формалар буенча һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык (электрон рәвештә һәм кәгазьдә) тапшыра.

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече – урнаштырылган бюстлар саны (кимендә 1 берәмлек).

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

14. Вәкаләтле орган Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. Әгәр башка бюджетара трансфертлар бирелгән елның 31 декабре хәленә карата муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган һәм башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елда килешү нигезендә башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирелә торган беренче датага кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

16. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидияләр максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы муниципаль берәмлекнең башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерә.

18. Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланылмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

19. Башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә түләтелергә тиеш.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---